60 нчы номерлы муниципаль автоном «Шәүләгән» балалар бакчасы

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре

Сәхнәләштерелгән әкият

# ***<u>Тема:</u> Ялгышмасам – үрнәк булсын,***
# ***Ялгышсам – гыйбрәт булсын!***

Әзерләде: 1 нче категорияле тәрбияче

Сарварова Сәвия Мингазовна

мәктәпкә әзерлек төркеме

Сәхнәләштерелгән әкият:

Х. Такташ «Тәүфыйклы песи». М. Җәлил «Карак песи».

# Тема: Ялгышмасам – үрнәк булсын, Ялгышсам – гыйбрәт булсын!

**Максат:** Сәхнә әсәре аша балаларның алган белемнәрен куллана белү күнекмәләрен, үз-үзеңне тоту, оялчанлык камилләштерү. Диалогик сөйләм телен, иҗади сәләтен үстерү. Балаларда мөстәкыйльлек, җаваплылык тәрбияләү.

**Лексик доза:** йон, җеп, орчык, тәуфыйк.

**Матур әдәбият:** К. В. Закирова «Балачак аланы»

**Методик алымнар:** Х. Такташның «Тәүфыйклы песи», М. Җәлилнең «Карак песи» - әкиятләрен уку, рәсемнәрен, иллюстрацияләрен карау; авыл өе күренешләрен карау.

**Индивидуаль эш:** Тычкан булып уйнаган балалар белән җырлап, хәрәкәт итүне өйрәнү.

**Коммуникатив эшчәнлек башкару:** әкиятне уку, шигырьләр уку, мәкальләр өйрәнү, үртәүчләр кабатлау.

## Эшләнелгән эшләр.

Халык әкиятләре белән таныштырып торабыз. Матур әдәбият геройлары аша төрле начар сыйфатларга, аларда дөреслек – ялган, яманлык, кешелеклелек, гаделлек, намуслылык һәм башка сыйфатлар берсе икенчесенә каршы килүен аңлату.

# Ялгышмасам – үрнәк булсын,
# Ялгышсам – гыйбрәт булсын!

*Авыл күренеше, мыр-мыр килеп песи йоклый. «Йокла инде курчагым» җырының көе яңгырый.*

*Күзлек кигән, кулына төсле йомгаклар салынган кәрзин тотып, әби керә, песи янына килә, яратып карап тора, аны сыйпый.*

**Әби:** Минем песи гаҗәеп хыянәтсез
Мулла кебек тәуфыйк иясе:
Каймак куясыңмы ни куйсаң да
Һич кенә дә юк инде тиясе.

*Әби сөйләнә- сөйләнә бәйләргә утыра.*

**Әби:** Менә шулай итсәм матуррак була. Озакламый бәйләп бетерәм, Аллах боерса (*күзлеген күтәрә*)! Бәрәкәт песием дә торган икән (*песи әбигә сырпалана*).

**Песи:** Мияу, Мияу
Әбием, алтыным
Минем иң якыным
Яратам, яратам
Мин сине.
Әбием, син нишлисен?

**Әби**: Башмак бәйлим.

**Песи:** Ә башмакны нәрсәдән бәйлисең?

**Әби**: Җептән бәйлим. Менә кара (*курсәтә*).

**Песи:** Ә нәрсә соң ул җеп (*тотып карый*)?

**Әби**: Нәрсә дип соң? Менә сарыкның йонын аласың, яхшылап язасың, орчык белән эрлисең, йомгакка урыйсың. Менә шул була инде җеп.

**Песи:** Әбием, минем дә йоным бар ич, минекен дә кыркыйсыңмы?

**Әби**: Юк ла! Үз йонын үзеңә булсын, песи йоныннан берни дә бәйләп булмый. Хәсрәтләнмә юк өчен. Кәрзинемне шунда калдырыйм да, печән бирим малкайларыма ( *чыгып китә*).

**Песи:** Ә мин әби җаным, син килгәнче
Йоклап алыйм әле әз генә (*ята*).

*Әкрен генә аяк очларына басып тычканнар керә.*

**1 нче тычкан:** Пи-пи-пи
**2 нче тычкан:** Тссс, тавышланма, песине уятырсың.

**2 – се бергә:** Нинди матур өй.

*Тычканнар башкаруында «Песи һәм тычканнар җыры».*

*2-се бергә җырлыйлар:*

Мияу-мияу, мияулап,
Мич башында йоклаган.
Бүген тычкан тотмаган,
Тотар иде – йоклаган.
Песи-песи, поскан
Ике күзен кыскан,
Кысса – безне тоталмый,
Тотар инде җитә алмый.

*Песинең койрыгыннан тоталар. Ул уяна.*

**Песи:** Мияу! Ах, сез шаяннар! (*Тычканнарны куып тота*).

**Тычканнар:** Гафу ит безне, Мырауҗан без бүтән алай эшләмәбез.
Йомгакларны җыябыз. (*Йомгакларны җыеп кәрзингә салып, песигә бирәләр)*.

**Песи:** Тычканнар, әйдәгез, дус яшик! (*тычканнар чоланга кереп китәләр.)*

*Әби керә, песи ялкауланып ята.*

**Әби**: Тамагым бик кипте, чәй эчим әле, эх чәе бигрәк тәмле!
**Песи:** Мияу!
**Әби**: Нәрсә кирәк пескәем!
**Песи:** Мияу!
**Әби**: Хәзер чоланнан сөт алып керәм үзеңә (*Әби чоланга чыга, анда тычканнар чабыша, әби шаккатып карап тора)*.

*Чолан күренеше тычканнар җырлап бииләр.*

Без тычканнар, күселәр
Чи-чи-чи киләбез,
Чоланга керү белән,
Майның исен сизәбез.

Әй алмагачлары
Шушы майның исләре.

*Әби өйгә керә.*

**Әби**: Мияу, мияу, пескәем.
Барчы, зинһар чоланга
Майны сакла күседән
Оясыннан чыгарма.

**Песи:** Песи өчен, нәрсә, ерак мена
Чолан белән бүлмә арасы
Тычканнарның нәрсә эшләгәнен
Башны гына тыгып карыйсы.

*Песи чоланга чыга, анда тычканнар йөгерешә.*
*Тычканнарнар җырлый.*

Ашыйк әле, ашыйк әле,
Ашыйк әле тагын да,
Ашамас идек тагын да,
Май бигрәк тәмле монда,
Әй, алмагачлары,
Шушы майның исләре.

*Песи әкрен генә килеп, икесенен ике колагыннан эләктереп ала.*

**Песи:** Әхә, эләктегезме караклар!
**Тычканнар:** Гафу ит безне, Мыраужан без бүтән алай эшләмәбез.(Песи, тычканнарны колакларыннан әби янына алып керә).
**Песи:**Әби, менә каракларны тоттым.
**Тычканнар:** Әби, Мыраужан сез безне гафу итегез, бүтән алай эшләмәбез.
**Песи:**Әби, без тычканнарны болай гына җибәрмик, алар безгә җырласыннар, биесеннәр.
**Песи:** Тычканнар, әйдәгез, дус яшик!
Бүтән алай алдашмагыз,
Бер нәрсә дә урлашмагыз.
**Тычканнар:** Юк-юк, бүтән урлашмыйбыз.
**Әби:** Халыкта шундый мәкаль бар:
Бер ялганласаң икенче ышанмаслар!
Тычканнар, сүз бирдегез, үтәгез!

*Тычканнар чоланга чыгып китәләр.*

**Песи:** Әби, син су алып кергәнче, чоланны карап керим әле. Тычканнарга ышаныч аз. *(Песи чоланга чыгып китә).* Әнә посканнар, койрыкларын кысканнар. Тынычлап йокларга да була *(песи ята).*

*Як-ягына карана-карана эт керә, песине күрә.*

**Эт:** И-и-и, бигрәкләр дә йокы чүлмәге инде әбинең песие. *(Чүлмәктәге майны күреп ала).* Тәмле әйбер ахры. Белер өчен кирәк, майны кабып карарга. Әйе кирәк. *(кабып карый).* Тәмле, бигрәк тәмле.

Песиләр шул тора беләләр,
Йонлы борыннар, эшләмичә
Каймак ашап рәхәт күрәләр.
Үз ояма алып чыгып ашыйм әле.

*Майга үрелгәндә өстәлдәге савыт төшеп ватыла, эт кача..Песи уяна. Әби керә.*

**Әби:** Әхә, кем икән ул явыз карак, сөт, каймакның башына җитүче, менә кем икән ул йортымдагы чүлмәкләрне харап итүче! Югал күз алдымнан ятсыз нәрсә. Кит хәзер үк чыгып өемнән!

*Песине куа, ул елап чыгып китә, эт яңадан керә.*

**Эт:** Май тәмле булды, кичкә ашарга тагын берәр нәрсә булмасмы? Әхә менә монсы ярый. *(сосисканы алып йөгерә, моны әби күреп ала.)*

**Әби:** *(башын тотып)* Ах, нишләдем мин?!
- Бер гаепсезгә песиемне куып чыгардым.
- Песием, песием, пес, пес, пес.
- Чыгып карыйм әле бәлки ерак китмәгәндер. *(чыгып китэ.)*

**Урман күренеше.**

*Песи елап бара, каршысына тиен чыга.*

**Тиен:** Песи, нигә елыйсың?
Нигә яман сулыйсың?
Күзләреңнән яшь тама,
Сөйлә, ни булды сиңа.

**Песи:** Еламыйча нишлим соң?
Майны маэмай ялады,
Кайда май дип сорагач,
Миңа якты ялany.

**Тиен:** Төзәтергә кирәк хатаны!

- Нишлим микән соң? Ә-ә, тукта әле, мин сызгырып башка җәнлекләрне чакырам. *(Сызгыра. Куян, төлке, бүре, аю, керпе чыгылар.)*

**Җәнлекләр:** Кемнәр монда тавышлана,
Кем йокыдан уятты?
Сезнең тавыш шундый каты,
Авырттырды колакны.

**Тиен:** Песи, нигә елыйсың?
Нигә яман сулыйсың?
Күзләреңнән яшь тама,
Сөйлә, ни булды сиңа.

**Песи:** Еламыйча нишлим соң?
Майны маэмай ялады,
Кайда май дип сорагач,
Миңа якты яланы.
Әби куып чыгарды-ы-ы *(елый)*

**Бүре:** Песи елама, әйдә кара-каршы әйтешәбез!

- Песи кая барасың? – Әбиләргә барамын.
- Анда сиңа ни тия? – Ике калак май тия.
- Аны кая куярсың? – Мич астына куярмын.
- Пычранса, нишләрсең? – Суга төшеп юармын.
- Төшеп китсәң, нишләрсең? – Талга ябышып чыгармын.
- Талың купса, нишләрсең? – Акырып-бакырып еларрмын.

*Песи һаман елый. Керпе аны үрти.*

**Керпе:** Җылак, җылак, җылак колак.
Йомарлада мичкә як.
Җылак, җылак, салпы колак.
Карама таяк, карт әтәч.
Җылак, җылак, җылкыткан.
Җылап кеше куркыткан.

**Төлке:** Кит әле, моннан керпе, үртәп торма. Песи, елама без сиңа такмаклар җырлыйбыз.

Иртән торып тышка чыксам,
Сыерлар кар көриләр,
Ике куян мылтык тотып
Бүре атып йөриләр.
Миндә гайрәт, миндә көч,
Миннән курка үрмәкүч
Мич башына менгән идем,

Салып екты үрмәкүч.
Ике чебен идән юа,
Итәкләрен кыстырып.
Ата чебен кара пята,
Мич башыннан сызгырып.
Безнең песи бигрәк уңган,
Тәпәнгә су тутыра,
Бозавыбыз мич башында
Оек бәйләп утыра.

**Аю:** Песи, елама инде, мин сиңа такмаза сөйлим.

Бардым борчакка, төядем корсакка,
Килеп чыкты иясе, инде нәрсә диясе?
Килеп чыкты Фазлый, менә мине каезлый,
Килеп чыкты Миргали, менә миңа бәргәли,
Килеп чыкты Шәвәли, менә мине әвәли,
Килеп чыкты Муса, менә мине кыса.
Килеп чыкты Әпәли, менә мине әпәли,
Килеп чыкты Йосып, үтерә язды кысып,
Алып китте тотып, ул илтте үрәтниккә
Үрәтник әйтә: «Атам!» - ди.
Мин чыгып йөгердем: «Кайтам!» - ди.

*Песи көлә башлады.*

**Песи:** Рәхмәт сезгә, минем күңелемне күтәрдегез.
Әйдәгез, мин сезнең белән уен уйныйм. Ул « тавышымны таны» дип атала.

*Әби керә.*

**Әби:** Нинди матур урман! Тик миңа гына ямансу (елый).
**Җәнлекләр:** Әби син нишләп йөрисең урманда? Нигә елыйсың?
**Әби:** Кайгым зур минем: бер гаепсезгә песиемне куып чыгардым, ялгышлык эшләдем. Сез күрмәдегезме аны, җәнлекләр?
**Җәнлекләр:** Күрдек, күрдек!
**Әби:** Кайда ул минем песием – Мыраужаным? Күрсәтегез миңа!

*Песи чыга, әби белән кочаклашалар, елашалар.*

**Әби:** Гафу ит мине, песием.
**Песи:** Мияу-мияу*! (Әбигә сырпалана).*
**Әби:** Минем песием гаҗәеп хыянәтсез,
«Мулла» кебек тәүфыйк иясе,
Каймак куясыңмы, ни куйсаң да,

Һич кенә юк инде тиясе.

**Төлке:** Әби, балаларның уйныйсы килә. Менә монда ике төрле песи рәсеме, шуларны кисәкләрдән дөрес итеп җыярга кирәк. *(Балалар җыялар.)* Әби кара әле, кайсы синең песиеңә ошаган?

*Әби күрсәтә, шуннан соң үзенең песие чыга.*

.

**Әби:** Дусларым, минем кебек ялгышлык эшләмәс өчен, башта уйларга кирәк, соңыннан үкенерлек булмасын. Халыкта шундый мәкаль бар: «Җиде кат үлчә – бер кат кис». Мин бу мәкальләрне беләм, ә сез беләсезме?

*Әби мәкаль әйтә башлый, башкалар әйтеп бетерә.*

**Әби:** Берәү кеше ялгышын өйрәнә…
Берәү үзе ялгыша-ялгыша өйрәнә.
**Әби:** Бер абынган чокырга…
Ике абынмыйлар.
**Әби:** Бер хата…
Ун хатадан саклый.,
**Әби:** Хатасын танымаган…
Тагын шул хатага төшәр.
**Әби:** Ялгышын таныган кеше…
Икенче ялгышмас.
**Әби:** Бик күп мәкальләр дә беләсез икән. Әйдәгез, хәзер биеп алабыз!

*Күмәк бию.*

**Әби:** Рәхмәт сезгә, урман җәнлекләре, миңа песиемне табарга булыштыгыз. Менә сезгә күчтәнәчләр, сыйланыгыз. Песиләрне, этләрне рәнҗетмәгез! Бер-берегезгә мәрһәмәтле булыгыз. Сау булыгыз! Безгә кунакка килегез!

*Әби песие белән китә.*